6+

ГАЗИНУР МОРАТ

# ТИЗРӘК ҮСӘСЕМ КИЛӘ!



ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат)-5
М66

«Сабыйларга бүләк» сериясе

Рәссамы *Илдус Әҗемов*

**Морат, Г. В.**

М66 Тизрәк үсәсем килә! : балалар өчен шигырьләр / Газинур Морат. — Казан : Татар. кит. нәшр., 2019. — 36 б., тышл. 6-н. («Сабыйларга бүләк» сериясе.)

ISBN 978-5-298-03853-9

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-03853-9

© Татарстан китап нәшрияты, 2019
© Морат Г. В., 2019

Литературно-художественное издание
Для детей дошкольного и младшего школьного возраста
Серия «Подарок малышам»

**Мурат** Газинур
(**Муратов** Газинур Васикович)

ХОЧУ БЫСТРЕЕ ВЫРАСТИ!

Казань. Татарское книжное издательство. 2019
На татарском языке

Әдәби-нәфис басма
Мәктәпкәчә һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен
«Сабыйларга бүләк» сериясе

**Морат** Газинур
(**Моратов** Газинур Васикъ улы)

ТИЗРӘК ҮСӘСЕМ КИЛӘ!

Мөхәррире *Р. Г. Сәлахов*
Бизәлеш мөхәррире *Р. Х. Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Г. С. Нуретдинова*
Корректоры *А. М. Закирова*

6+ Знак информационной продукции согласно ФЗ от 29.12.2010 г. №436—ФЗ

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 20.10.2019. Форматы 60×90 1/8. Шартлы басма табагы 4,5.
Тиражы 2500 д. Заказ № 23102019_1

«Татарстан китап нәшрияты» ТР ДУП.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.
Тел./факс: (843) 519-45-22.
**http://www.tatkniga.ru**
**e-mail: info@tatkniga.ru**

9 785298 038539

**Татарстан китап нәшриятының фирма кибетләре:**
Казан, Бауман урамы, 19. Тел.: (843) 294-70-50.
Казан, Бауман урамы, 51. Тел.: (843) 225-76-55.
Казан, Декабристлар урамы, 2. Тел.: (843) 519-45-13.

**Маркетинг бүлеге:**
Казан, Декабристлар урамы, 2. Тел.: (843) 519-45-35.

**Интернет-кибет:**
**http://www.tatkniga.ru**

Отпечатано в типографии ООО «МИР»
394033, г. Воронеж, Ленинский пр-т 119 А, лит. Я, оф. 215

# ЭЧТӘЛЕК


Иң кыены кайсы дәрес? . . . . . . . . . . . . . . . 3
Татар космонавты . . . . . . . . . . . . . . 4
Төшләр күрдем . . . . . . . . . . . . . . . 5
Абага . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 6
Бабам авырып ята . . . . . . . . . . . . . . 8
Сүз боткасы . . . . . . . . . . . . . . . . 9
Язгы сурәт . . . . . . . . . . . . . . . . 10
Иң матур ил . . . . . . . . . . . . . . . . 11
Шәһәр аты . . . . . . . . . . . . . . . . 12
Яңгырдан соң . . . . . . . . . . . . . . . 12
Рәсем . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Табигать белеме . . . . . . . . . . . . . . 14
Хезмәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
Ачык дәрес . . . . . . . . . . . . . . . . 16
Чит тел . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
Туган телен күмгән тавык . . . . . . . . . . 18
Гашыйк малай . . . . . . . . . . . . . . . 20
Физкультура . . . . . . . . . . . . . . . . 21
Ләйсән йолдыз . . . . . . . . . . . . . . . 22
Очу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
Туган тел . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
Зоопаркта . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Үзгәрдем . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
Тылсымлы тел . . . . . . . . . . . . . . . 26
Хәрәкәттә — бәрәкәт . . . . . . . . . . . . 27
Йолдыз илчеләре . . . . . . . . . . . . . . 28
Уен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 30
Арифметика . . . . . . . . . . . . . . . . 31
Курчак . . . . . . . . . . . . . . . . . . 32
Диңгез истәлеге . . . . . . . . . . . . . . 33

## ИҢ КЫЕНЫ КАЙСЫ ДӘРЕС?

Иң кыены кайсы дәрес? —
Белмим ул кадәресен.
Кемгә физикадыр, бәлки,
Ә миңа — җыр дәресе.

Ник дисезме — җырлый белмим,
Көем чыкмый — көйләсәм.
— Колагыңа аю баскан, —
Дип үрти мине Ләйсән.

Үртәсен лә, әйдә,
Мине
Юри үртәли ич ул.
Берәр кыек сүз әйтсәм дә,
Юри үпкәли ич ул.

Хәер, ансы мин үзем дә
Җырламыйм юри генә.
Күңелем тулы җыр минем...
Тик Ләйсән күрми менә...
Тик Ләйсән белми генә...







## ТАТАР КОСМОНАВТЫ

Ник Галәмгә очмый татар?
Уйлыйм гел шул турыда.
Ахры, миңа туры килер
Космонавт булырга.

Кемдер әйтер, хыялый, дип,
Кемдер әйтер — төшләнә.
Юк, төшләнмим.
Зөһрә кызны
Айдан алып төшәргә,

Ахры, миңа туры килер.
(Әнә йолдыз атыла!..)
Булачак, димәк, туачак
Татар космонавты да!

Кабул кылынсын теләгем
Йолдыз атылган мәлдә.
Галәмдә — татар, дисәләр,
Мин булырмын Галәмдә.